**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2023 елның «26» маеннан № 34-267

2022 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнарында коррупциянең торышы һәм аларның эшчәнлеген киметү буенча гамәлгә ашырыла торган чаралар һәм 2023 елга бурычлар турында

2018 елның 24 сентябрендәге ПР-271 номерлы Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору буенча эшне координацияләү комиссиясе утырышы беркетмәсенең 3.1 п. нигезендә һәм Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ярдәмчесенең 2022 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнарында коррупциянең торышы һәм аларның эшчәнлеген киметү буенча гамәлгә ашырыла торган чаралар һәм 2023 елга бурычлар турында докладын тыңлаганнан соң, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Яңа Чишмә муниципаль районында 2022 елда коррупциянең торышы һәм коррупцион шартларны киметү буенча күреләә торган чаралар турында мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ярдәмчесенә, Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнарында коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка:

- коррупциягә каршы муниципаль программаны комплекслы тормышка ашыруны, шул исәптән хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы мәгълүматларның тулылыгын һәм дөреслеген, коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән тыюларны, чикләүләрне һәм таләпләрне үтәүләрен анализлау һәм тикшерү үткәрүне тәэмин итәргә;

- Яңа Чишмә районы хезмәткәрләрен һәм халкын хокукый һәм коррупциягә каршы агарту максатыннан конференцияләр, түгәрәк өстәлләр һәм фәнни-гамәли

семинарлар үткәрү өлешендә гражданлык җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлек эшен көчәйтергә;

- гражданнарда, шул исәптән яшьләр даирәсендә, студентлар һәм эшче яшьләр арасында коррупцияне кабул итмәүне тәрбияләү буенча иҗтимагый оешмалар белән эшне көчәйтергә;

- коррупциянең торышы турында объективрак мәгълүмат алу һәм аны киметү буенча гамәлгә ашырыла торган чараларның нәтиҗәлелеген арттыру максатында коррупциягә каршы мониторинг һәм социологик сораштырулар үткәрү методикасын камилләштерергә.

3.Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнарында коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар, шулай ук ведомство буйсынуындагы оешмалар җитәкчеләре эшчәнлегендә коррупцион куркынычлар барлыкка килүгә китерә торган мәнфәгатьләр конфликтын һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча чаралар күрергә.

4. Әлеге карарны «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районы рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль
районы Башлыгы В.М. Козлов